ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апреля 2026 ел № 89

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда туклану, яшәү, юл йөрү, Бөтенроссия олимпиадаларының төбәк этабын һәм республика олимпиадаларының йомгаклау этабын уздырганда команда җитәкчеләрен һәм фән олимпиадаларында катнашучыларны туклandыру һәм яшәү чыгымнары тәртибен раслау турында» 2026 елның 04 февралендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә мәдәни-массакүләм чараларны матди яктан тәэмин итүгә каралган акчаларны рациональ файдалану, 2025-2026 уку елында мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны туклandыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 04 февралендәге 23 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда туклану, яшәү, йөрү чыгымнарын тәэмин итү, Бөтенроссия олимпиадаларының төбәк этабын һәм республика олимпиадаларының йомгаклау этабын уздырганда командалар җитәкчеләренә һәм фән олимпиадаларында катнашучыларга туклану һәм яшәү чыгымнарын түләү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Мәдәни-массакүләм чаралар уздырганда катнашучыларны туклandыру, юл йөрү һәм яшәү белән тәэмин итүгә чыгымнар нормативларын» турындагы 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «

| № | Мәдәни-массакүләм чаралар исеме. | Көнгә бер кешегә чыгымнар нормалары (сум) |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районыннан 200 км һәм аннан да күбрәк ераклыкта уздырылган, кимендә 3 сәгать дәвам итуче чараларда катнашучыларны тукландыру | 400 |
| | Катнашучыларны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районыннан 200 км һәм аннан да күбрәк ераклыкта тукландыру | 400 |
| | Катнашучыларның чара үткәрелгән урында яшәве:<br>- Татарстан Республикасы территориясендә;<br>- РФ территориясендә, Татарстан Республикасы чикләреннән тыш | <br><br>2500<br><br>2500 |
| | Юл түләме өчен | Юл документлары белән расланган факттагы чыгымнар күләмендә |

Искәрмә: оештырылган туклану белән тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда мәдәни-массакүләм чаралар үткәрелгән урыннарда акчасыз исәп-хисап буенча мәдәни-массакүләм чаралар үткәрелгәндә, ведомость буенча акчаларны югарыда күрсәтелгән нормалар буенча бирергә рөхсәт ителә».

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карар нигезендә чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Үзәкләштерелгән бухгалтерия” муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә әлеге карар нигезендә чыгымнарны вакытында түләргә.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче урынбасары** **Р.Н. Бадахшин**